ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2021 г. Заинск №438

**«Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 8 июнендәге 339 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләре һәм тәртибе турында» 2021 елның 28 октябрендәге 1009 номерлы карарны үтәү йөзеннән, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 29 декабрендәге 2901 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 8 июнендәге 339 номерлы карары белән расланган Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 1.5. пунктындагы 4 пунктчасын яңа редакциядә укырга: аны турыдан-туры тормышка ашыру максатларында «Татарстан Республикасында

торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән махсуслаштырылган оешма - республика коммерцияле булмаган оешмасы яки Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан төзелгән яисә вәкаләтле орган.

1.2. 3 бүлекнең 3.6.1 пунктындагы 4 пунктчасында «ГЖФ» сүзен "Махсуслаштырылган оешма" сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 3 бүлекнең 3.6.1 пунктындагы 3 пунктчасында «ГЖФ» сүзен "Махсуслаштырылган оешма" сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 1 кушымтада гариза башында «(адрес буенча теркәлгән: почта индексы, тулы адрес)» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.5. 3 кушымтада «теркәлгән» сүзен «яшәүчеләр» сүзенә алмаштырырга.

1.6. 4 кушымтада «теркәлгән» сүзен «яшәүчеләр» сүзенә алмаштырырга.

1.7. Күрсәтелгән регламентны 7 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта бирелә).

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
7 07 75
Юрист

2021 елның 13. 12.

738 номерлы карарга кушымта

Татарстан Республикасында Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 7 кушымта

Мөрәҗәгать итүчене һәм аның гаиләсен социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлеге

1. Гражданның җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә оешма җитәкчесе исеменә гаризасы;

2. Россия Федерациясе территориясендә яшәүче мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе гражданының һәм аның 14 яшьтән өлкәнрәк гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлары;

3. Торак урынның яши торган һәм гомуми мәйданнарын күрсәтеп, финанс-лицевой счеты;

4. Гаилә составын билгели торган документлар:

4.1. мөрәҗәгать итүченең 14 яшькә җитмәгән барлык гаилә әгъзаларының туу турында таныклыклары;

4.2. Никахлашу факты булганда мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен никахлашу турында таныклык;

4.3. Ата булуны билгеләү факты булганда, ата булуны билгеләү турында таныклык;

4.4. Күрсәтелгән чорда аерылышу факты булганда, әгәр аерылышу вакытыннан соң 5 ел узмаган булса, никах таркалу турында таныклык;

4.5. Фамилия, исем, әтисенең исеме үзгәрү факты булганда фамилия, исем, атасының үзгәрүе турында таныклык;

4.6. Гаилә составын раслау өчен үлем факты булганда үлү турында таныклык;

4.7. Күрсәтелгән суд карары булганда ата булуны билгеләү турында яисә ата булуны тану фактын билгеләү турында законлы көченә кергән суд карары;

4.8. Күрсәтелгән суд карары булганда мөрәҗәгать итүчегә һәм/яисә мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларына карата туганлык мөнәсәбәтләрен билгеләү яисә туктату, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, вафат дип тану, хәбәрсез юкка чыккан дип тану турында закон көченә кергән суд карары (суд карарын кабул иткән суд тарафыннан таныкланган күчермә).

5. Торак шартларын раслый торган документлар:

5.1. Аерым затның үзендә булган (булып торган) күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә (соңгы 5 ел өчен);

5.2. Мөрәҗәгать итүченең, аның гаилә әгъзаларының булган күчемсез мөлкәт объектларына аларга хокуклар күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән хокукны билгели торган документлары яисә аларның нотариаль таныкланган күчермәләре (торак бинага һәм (яисә) җир кишәрлегенә милек хокукы турында таныклык, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итеп бирү шартнамәсе һ.б.);

5.3. Ордер (наем, поднайм, аренда, субаренда шартнамәсе);

5.4. Торак бинага хокук күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән очракта, торак бинаның (фатирның) техник планы яки техник паспорты;

5.5. Күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

5.6. Торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында белешмәләр.

6. Керемнәр төрләрен һәм күләмен раслый торган документлар:

6.1. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 661 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт кенәгәсе (эш бирүче раслаган барлык битләрнең күчермәсе) һәм яисә тиешенчә таныкланган кәгазьдә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә белшмәләр;

6.2. Студент билеты яисә уку урынын раслый торган документ (укучылар өчен);

6.3. Хәрби хезмәт узу турында белешмә;

6.4. Һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына һәм дини мәгариф оешмаларында укучыларга түләнә торган стипендия күләме турында белешмә яисә тиешле белем бирү оешмасы тарафыннан бирелгән медицина күрсәткечләре буенча академик ялда булган чорда гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләрен бирү турында белешмәләр (тиешле түләү алучы затлар өчен);

6.5. Махсус салым режимнарын кулланучы физик затларның, индивидуаль эшкуарларның керемнәре турында белешмәләр

6.6. Физик затлар файдасына иминият взнослары түләүчеләр тарафыннан башкарылган түләүләр, пенсияләр, пособиеләр һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яки) Татарстан Республикасы законнары нигезендә алынган түләүләр рәвешендә социаль ярдәмнең башка чаралары турында белешмәләр;

6.7. Пособие билгеләү турында белешмәләр;

6.8. Салым органнарында исәпкә кую турында белешмәләр;

6.9. Индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу системасында теркәлү турында белешмәләр;

6.10. Иминият стажы турында белешмәләр;

6.11. Опека һәм попечительлек органы актыннан опекун билгеләү турында белешмәләр.

7. Ташламаларга ия булганда:

7.1. Гражданның социаль ярдәм алу хокукын раслый торган дәлилләре һәм документлары;

7.2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алына торган затлар өчен өстәмә мәйданга хокук турында документлар, әлеге хокукны исәпкә алып.

8. Яшәү (булу) урыны турында белешмәләр;

9. Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар булмау турында гаиләнең барлык әгъзаларына салым органы белешмәләре.

10. Оешма хезмәткәрен социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу турында җирле үзидарә органы җитәкчесе адресына үтенечнамә.

Әлеге кушымтаның 3 пунктында, 4 пунктның 4.1 – 4.6 пунктчаларында, 5 пунктның 5.1, 5.5, 5.6 пунктчаларында, 6 пунктның 6.5 – 6.11 пунктчаларында, 8, 9, 10 пунктларында күрсәтелгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) җирле үзидарә органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша мөстәкыйль рәвештә, шул исәптән исәпкә алынуны яңадан теркәгәндә, соратып алына. Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.